КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 ноябрь г.Казань № 1037

Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 ноябрь, 1037 нче
карары белән расланды

Төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында төбәк компетенцияләр үзәкләренең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыру буенча эшчәнлеген оештыруга һәм тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

Бу Тәртипне куллану максатларында төбәк компетенцияләр үзәге – ул үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә башкаручы, гамәлгә куючыларының берсе Татарстан Республикасы булган коммерциягә карамаган оешма (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм (яки) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларын тормышка ашыручы, гамәлгә куючысы бары Татарстан Республикасы гына булган оешма дигәнне аңлата.

Бу Тәртипне куллану максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чаралары кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультация ярдәме һәм башка төрле ярдәм күрсәтүгә, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән заказчылар, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә җитештерүне гамәлгә ашыручы яки локальләштерүче, еллык табыш күләме 2 млрд.сумнан артыграк булган башка компанияләр, шул исәптән чит илләр катнашындагы компанияләр тарафыннан товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр сатып алу гамәлгә ашырылганда тәэмин итүчеләр буларак кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүне стимуллаштыру максаты белән ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы (алга таба – «үстерү» чаралары) дигәнне аңлата.

2. Субсидияләр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бирелә, аңа бюджет акчасын алучы буларак Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

3. Субсидияләр Министрлык белән еллык табыш күләме 2 млрд.сумнан артыграк булган компания арасында «үстерү» чараларын тормышка ашыру кысаларында үзара хезмәттәшлек турында кимендә бер өчьяклы килешү төзегән төбәк компетенцияләр үзәгенә бирелә.

4. Субсидияләр аны бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айның беренче көненә туры килә торган төбәк компетенцияләр үзәгенә бирелә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәсе булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясенең Финанс министрлыгыраслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 процентттан артып киткән Россия юридик заты булмаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алмаган.

5. Субсидияләр исәбеннән финанслар белән тәэмин ителергә тиешле төбәк компетенцияләр үзәге чыгымнарының юнәлешләре түбәндәгеләр була:

а) төбәк компетенцияләр үзәге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнары;

б) элемтәне тәэмин итү чыгымнары;

в) офис җиһазы, электрон-хисаплау техникасы (мәгълүматны эшкәртү өчен башка җайланма), программа тәэминаты, периферия җайланмалары һәм күчермә-күбәйтү җайланмасы сатып алу чыгымнары;

г) коммуналь хезмәтләр өчен түләү һәм бина урыннарын арендалау чыгымнары;

д) башка агымдагы чыгымнар (командировка, канцелярия товарлары һәм чыгым материаллары сатып алу, автомобиль арендалау, махсуслаштырылган мәгълүмат системаларын файдалану чыгымнары, офис җиһазын ремонтлау һәм сервис хезмәте күрсәтү чыгымнары);

е) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү чыгымнары;

ж) «үстерү» чараларын, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының күргәзмә-ярминкә һәм коммуникатив чараларда, бизнес-миссияләрдә катнашуын оештыру һәм үткәрү, сайт һәм «үстерү» чараларын мониторинглауның мәгълүмат системасын булдыру, эшләвен тәэмин итү һәм аннан файдалану, эксперт һәм консультация хезмәтләре күрсәтү, укыту чараларын оештыру һәм үткәрү, презентация һәм мәгълүмати материаллар әзерләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар.

6. Субсидия алу өчен төбәк компетенцияләр үзәге Министрлыкка түбәндәге документларны үз эченә алган заявка тапшыра:

субсидия алуга гариза;

гамәлдәге гамәлгә кую документларының күчермәләре;

төбәк компетенцияләр үзәгенең бу Тәртипнең 3 нче пунктына туры килүен раслый торган документлар;

бу Тәртипнең 4 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килү турында гарантия хаты;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айның беренче көненә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмавын раслый торган белешмә кәгазе.

7. Чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алу өчен төбәк компетенцияләр үзәге бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнарның төбәк компетенцияләр үзәге җитәкчесе тарафыннан расланган сметасын тапшыра, аңа планлаштырыла торган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясен үз эченә алган, аларның күләмен дәлилләүче мәгълүмат күрсәтелгән финанс-икътисадый нигезләү теркәлә.

8. Чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алу өчен төбәк компетенцияләр үзәге бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта тотылган чыгымнарны раслый торган документларны (чыгымнар сметасын, шартнамәләр һәм аларга кушымталарны, түләү документларын (түләү йөкләмәләрен, керем һәм чыгым ордерларын), эш хакына исәпләүләр исемлеген, аванс хисапларын, счет-фактураларны, башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) актларын, йөкнамәләрне) тапшыра.

9. Документлар төбәк компетенцияләр үзәге тарафыннан кәгазь һәм электрон чыганакларда тапшырыла.

Кәгазь һәм электрон чыганакларда тапшырылган барлык документлар төгәл басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми (төбәк компетенцияләр үзәгенең вәкаләтле заты имзасы белән расланган һәм мөһере (булганда) сугылган төзәтүләрдән тыш). Кәгазь чыганакта тапшырылган заявканың барлык битләре нумерланган булырга тиеш. Кәгазь чыганакта тапшырылган заявка тегелгән һәм төбәк компетенцияләр үзәгенең вәкаләтле заты имзасы белән расланган

һәм заявканың ахыргы битенә, битләрнең гомуми санын күрсәтеп, мөһере (булганда) сугылган булырга тиеш.

Төбәк компетенцияләр үзәге тарафыннан бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы алтынчы абзацы белән күздә тотылган документ тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

10. Министрлык:

заявканы ул кергән көнне заявкаларны теркәү журналында теркәүгә ала, ул нумерланган, тегелгән һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш;

теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

төбәк компетенцияләр үзәгенең бу Тәртипнең 3 нче һәм 4 нче пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы икенче – бишенче абзацларында, бу Тәртипнең 7 нче пунктында (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алу өчен заявка бирелгән очракта), бу Тәртипнең 8 нче пунктында (чыгымнар каплауга субсидия алу өчен заявка бирелгән очракта) күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

тапшырылган документларның, алардагы мәгълүматларның бу Тәртип белән күздә тотылган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

төбәк компетенцияләр үзәге тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә бу турыда төбәк компетенцияләр үзәгенә хәбәрнамә җибәрә.

12. Субсидия бирү өчен Министрлык һәм төбәк компетенцияләр үзәге арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә торган килешү нигез булып тора.

13. Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар (каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар) юнәлешләре, субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре, субсидия күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану һәм субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар тапшыру вакытлары һәм формалары, субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары һәм тәртибе, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт (Министрлык тарафыннан аларны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә), алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю (югары технологияле чит ил җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш)

турындагы нигезләмәләр, Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан аны бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыру өчен субсидия бирү турындагы килешү йөкләмәләрен үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, үтәүчеләр) булган затларның һәм төбәк компетенцияләр үзәгенең ризалыгы, бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр карала.

Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

«үстерү» чаралары кысаларында Индивидуаль үсеш карталары эшләнгән һәм расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны;

«үстерү» чаралары кысаларында «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге ФЗ-223 номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән заказчыларның сатып алуларында катнашуга рөхсәт ителгән һәм заявка тапшырган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны.

Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәләре килешүдә Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

14. Чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$С_{фо} = Р_1 + Р_2 + Р_3 + ... + Р_n,$$

монда:

$С_{фо}$ – субсидия күләме;

$Р_1$, $Р_2$, $Р_3$ ... $Р_n$ – чаралар оештыру һәм үткәрү чыгымнарының бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бирелә торган субсидия исәбеннән финанслар белән тәэмин ителергә тиешле, законнар нигезендә төзелгән һәм Министрлык белән килештерелгән сметасы нигезендә билгеләнә торган чыгымнар.

Чыгымнарны каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$С_{вз} = З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n,$$

монда:

$С_{вз}$ – субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$ ... $З_n$ – компетенцияләр төбәк үзәгенең бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча «үстерү» чараларын тормышка ашыруга бәйле фактта тотылган чыгымнары.

Персоналның субсидия хисабыннан финанслар белән тәэмин ителергә (капланырга) тиешле хезмәте өчен түләү чыгымнары хезмәткәрләрнең исәпләнгән саныннан, исәпләнгән вазыйфаи окладлардан, вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләүләрдән, стимуллаштыра торган түләүләрдән, шулай ук Россия Федерациясе законнары, расланган штат расписаниесе нигезендә төбәк компетенцияләр үзәгенең локаль норматив актлары белән күздә тотылган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә.

Субсидия хисабыннан финанслар белән тәэмин ителергә (капланырга) тиешле төп чаралар, матди запаслар сатып алу чыгымнары тәңгәл (бер үк төрле) товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче оешмаларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарындагы, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларындагы һәм махсус әдәбияттагы (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт базар бәяләрен чагыштыру (базарны анализлау) ысулы белән билгеләнә.

15. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә килешү проекты Министрлык тарафыннан төбәк компетенцияләр үзәгенә имза куюга җибәрелә.

16. Килешүгә төбәк компетенцияләр үзәгеннән имзасы куелган килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык тарафыннан имза куела.

17. Министрлык килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә төбәк компетенцияләр үзәгенең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына субсидия күчерә. Төбәк компетенцияләр үзәге Министрлыкка килешү белән күздә тотылган форма, вакытлар һәм тәртип нигезендә финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар турында хисап һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында хисап кертергә тиеш.

18. Төбәк компетенцияләр үзәге тапшырыла торган мәгълүматлар дөрес булмаган һәм субсидиядән максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү шартлары төбәк компетенцияләр үзәге тарафыннан бозылган, нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

19. Килешү белән күздә тотылган очракларда, чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә бирелгән, хисап финанс елында төбәк компетенцияләр үзәге тарафыннан файдаланылмаган субсидиянең калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемено (Министрлык тарафыннан әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш) кире кайтарылырга тиеш.

20. Субсидияне, бу Тәртипнең 18 нче һәм 19 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидиянең калган өлешен кире кайтару вакытлары бозылган очракларда, Министрлык субсидияне, субсидиянең калган өлешен кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Россия Федерациясе законнары әлеге акчаны мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.